МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.08.2025 Казан ш № 497

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 634 номерлы боерыгы белән расланган Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламентына үзгәреш кертү хакында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 634 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 09.07.2015 №461, 09.11.2015 №821, 07.06.2016 №317, 20.07.2016

№420, 28.11.2016 №668, 27.02.2017 №104, 08.06.2017 №349, 28.05.2018 №401, 18.09.2018 №857, 04.02.2019 №77, 07.05.2019 №322, 10.09.2019 №689, 14.11.2019 №1021, 24.03.2020 №192, 13.07.2020 №502, 02.10.2020 №691, 24.02.2021 №102, 21.05.2021 №331, 06.08.2021 №567, 01.10.2021 №710, 13.04.2022 №273, 18.11.2022 №1030, 23.08.2023 №695, 10.01.2024 №3, 13.05.2024 №350, 30.05.2024 №394 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламентына үзгәреш кертеп, 1.2 пунктның 38 пунктчасында «социаль хезмәтләр күрсәтү дәүләт системасы социаль хезмәткәрләре» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү дәүләт учреждениеләренең социаль хезмәткәрләре һәм карау буенча ярдәмчеләре» сүзләренә алмаштырырга.

Министр Э.Ә. Зарипова